**Республика Татарстан**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**КАРАР**

«31» гыйнвар 2020 ел

№ 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе Л.И.Шәрипова

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 118,88 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3337,75 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1069,88 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1598,35 |
| Барлыгы | 6124,86 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесенең
2020 елның 31 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 118,88 |
| 2. Кәфенләү | 589,69 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2748,06 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1069,88 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1598,35 |
| Барлыгы | 6124,86 |